## Котлыйбыз!

### Балыклы авылы мәчете имамы Шәрифулла хәзрәт Сафиуллинга — 75 яшь!



### Хөрмәтле хәзрәтебез!

Сез олы тормыш юлы үткәнсез. Гомерегезнең төп өлеше шәһәрдә үтсә дә, лаеклы ялга чыккач, туган авылыгыз Балыклыга кайтып, анда яшәүче халыктагы динлелекне үстерүгә, аларга рухи тәрбия бирүгә һәм гореф-гадәтләрне саклауга күп көч куйдыгыз. Мәчетне, мәхәллә эшчәнлеген законлаштыру буенча да зур эшләр башкардыгыз. Сез - районыбыз авылларындагы имамнар арасында да хөрмәт казанган дин әһеле. Олы яшьтә булуыгызга карамастан, мәхәллә рәисе һәм мөәзин вазыйфасын да үз өстегезгә йөкләгәнсез. Сезнең үтемле вәгазьләрегез халык күңеленә нурлы, киңәшләрегез акыллы, йөзегез ягымлы һәм күңелегез саф. Сез - үрнәкле гаилә башлыгы, булдыклы ир, сөекле әти һәм бабай. Киләчәк тормышыгызда Сезгә Аллаһы Тәгаләдән исәнлек, озын гомер, гаилә бәхете телибез.

***Хатыныгыз, балаларыгыз, авылдашларыгыз һәм төбәгебездәге мөселман кардәшләрегез исеменнән Камышлы районы имам-мөхтәсибе Габдулла хәзрәт Мөхәмматкәрим.***

**Дин чыганаклары**

# Камышлы авылы мәчетләре тарихы



Сәйфулла мәчете

Татарлар кайда гына килеп утырсалар да, яңа тормыш башлаганда аларның иң беренче хыяллары мәчет төзү булган. Чиксез авырлыклар, ялангачлык чорында, ачлы-туклы заманнарда да аларда мәчет булдыру өмете сүрелмәгән.

Камышлы авылында Ислам диненә кагылышлы хәлләрне, мәчетләр тарихы хакындагы хәбәрләрне Саҗит хәзрәт Гусамов һәм аның хатыны Минҗиһан абыстай туплаганнар.

Элегрәк Камышлы авылы хәзерге урыныннан төньяктарак урнашкан булган. Бик борынгы заманнарда ук анда мәчет булуы турында хәбәрләр сакланган. Шуларның берсе 1681 елда салынганлыгы һәм анда беренче имам булып Габделгадиз хәзрәт эшләгәне билгеле. Бу мәчет калкурак урында урнашкан була. Зур янгын вакытында ул янып бетә. 1762 елда аның урынында хәзерге көнгәчә сакланып килгән башка мәчет корыла. Бирегә имам булып башта Стәрлетамактан Нәдер хәзрәтне чакырталар. Аңардан соң имамлыкны Газизҗан, Шәриф, Габретдин, Мингабиҗан, Зиннур, Шакир, Мөхәммәтгали, Әбүгали Әхмәтсафа, Габделәхәт, Миннәхмәт һәм Ибраһим хәзрәтләр алып баралар. Кызганыч ки, бу исемлектә 250 ел буена хезмәт иткән барлык имамнарның исемнәре дә билгеле түгел. Бу мәгълүматлар Саҗит хәзрәтнең әти-әнисе алып барган язмалардан гына алынганнар.

Бу мәчеттән башка Камышлыда тагын өч мәчет төзелә. Аларның берсе военкомат-суд бинасыннан түбәнрәк урнашкан. Аның тирәсендә зур мәйдан бар иде. Бу урын «Сок очы» дип аталды.

Икенче мәчет «Кара төп» чишмәсеннән түбәнрәк урында, соңгы вакытта базар урнашкан җирдә корылган булган. Өченчесе хәзерге Яңа мәчетебез урынында корылган иде. Алар дингә каршы каты көрәш барганда башка максатларда кулланылып, ахырда сүтеп алынып беттеләр.

Камышлыда берничә мәдрәсә дә булган. Мәсәлән, Нәҗип мулла мәдрәсәсе, Мисбах мулла мәдрәсәсе һәм башкалар.

Бу мәчетләрнең язмышы шушы авыл тарихына бәйләнгән. Торган саен алар турында мәгълүматлар онытыла бара. Авылның һәм андагы мәчетләрнең тарихы саклануны, аны ачыклап үстерүне мәктәпләр, мәдрәсәләр, мәхәллә халкы - һәрберсе үзләренең изге бурычы итеп куйсалар иде.

Авылда хезмәт иткән имамнарның бары тик үндүртесенең генә исемнәре билгеле. Аларны 1948 елда Мөхәммәтгали хәзрәт Шәрәпов башлаган. Революция чорында, аннан соңгы атеизм көчле заманнарда да



Иске мәчет

Камышлыда иске мәчет ябылмаган. Анда имамлыкны Зиннур, Шакир, Җәмил, Тәлгать, Габдерәхим, Миннәхмәт хәзрәтләр башкаралар. Озак еллар буена Сараҗ хәзрәт Вәлиәхмәтов, Миннәхмәт хәзрәт Сәлахов үз халкына хезмәт итәләр. Егерме ел буена Ибраһим хәзрәт Хәбибулин эшләгән. Соңгы елларда «Гали» мәдрәсәсен тәмамлаган Расих хәзрәт Вакказов, Ислам хәзрәт Баһаутдинов, Рамил хәзрәт Мингәрәев, Гомәр хәзрәт Яруллин эшлиләр. Бу чорда Минзәки хәзрәт Шәйхетдинов, Төркиядән килгән Мөхәммәт хәзрәт, Үзбәкстаннан Әбделкәрим хәзрәт һәм Минсәхи хәзрәт Бабретдинов та хезмәт итәләр. Җиде ел буена Мөхәммәтнәгыйм хәзрәт Вәлиәхмәтов эшли.



Городок мәчете

Муллалар нәселеннән булган Әхтәм хәзрәт Гусамовның авылдагы дин үсешенә керткән өлеше дә зур. Ул халыкка Ислам дине гыйлеме бирүгә күп көч куя, бигрәк тә мәктәп балаларына. Ул укыткан шәкертләр Казан һәм Уфа шәһәрләрендә үткәрелгән викториналарда, конкурсларда тәпле белем үрнәкләре күрсәтеп, һәрвакыт призлы урыннар яулап торалар.

Гомумән, авыллар һәм алардагы мәчетләрнең тарихын, дин әһелләренең язмышын ачыклау өчен зур тырышлык кирәк. Бу тема киң җәелдереп, тарихның тирән катламнарына төшеп, ачыкланып язылырга тиеш. Үз төбәгенең тарихын белеп тәрбияләнгән кешеләрдә генә үзенең туган ягына, үз халкына карата мәхәббәт һәм горурлык хисләре тәрбияләнүе мөмкин.

Имамнар үзләре эшләгән чорда кысрыклауларга, эзәрлекләүләргә карамастан, халыктагы динлелекне сакларга һәм үстерергә мөмкин булган кадәр тырышканнар. Аларны төрмәләргә утыртып, сөргеннәргә озатканнар, мыскыл итеп җәзалаганнар һәм үлемгә дучар иткәннәр. Без болар турында белергә тиешбез. Халыктагы динлелекне саклап көрәшкән каһарман имамнарның батырлыгы, тырышлыгы онытылырга тиеш түгел.

Үз халкының, туган җиренең тарихын белү - кешенең аң дәрәҗәсен үстерә, тормышка карашын һәм фикерләү офыгын киңәйтә, аның күңелен баета. Үз әти-әнисен, әби-бабасын, үз нәселен, авылдашларын хөрмәт итмәгән, үз төбәгенең тарихы, үз халкының язмышы турында уйлана белмәгән кешене тәрбияле, камил, акыллы, дип әйтеп буламы? Юк, әлбәттә!

***Үз хәбәрчебез.***

# Үткәннәрне белмәсәң, киләчәккә дөрес юл табу - авыр мәсьәлә

Сок елгасы буенда тезелеп утырган татар авылларының һәрберсенең үз тарихы бар. Алар бирегә иң дәһшәтле, коточкыч авыр заманнарда барлыкка килгәннәр. Җаннарын саклап татарлар арасына кушылып киткән Болгар иле халкы - чуашлар, марилар, удмуртлар да булганнар. Аларны Ислам дине үз канаты астына алган һәм бу халыклар татарлашып киткәннәр.

Һәр авылда борынгыдан ниндидер истәлекләр язылып, тарихи вакыйгалар теркәлеп килсәләр дә, алар хәзер таркалып, юкка чыгып баралар. Үз нәселе, авылы тарихы белән кызыксынучылар да бик аз.

Үз чорында Казан губернасының Бөгелмә өязенә, аннан соң Самара губернасындагы Богырыслан өязенә, ә соңрак Самара өлкәсенең Камышлы районына кергән авылларның тарихы катлаулы һәм фаҗигале.

Кызганыч ки, татар авыллары бергә тупланып яшәгән бу төбәкнең язмышын без хәзер бары тик рус хөкүмәтенең язмалары буенча гына белә алабыз. Мәсәлән, Казан ханлыгы алынып, бер гасыр вакыт үткәч, 1657 елда Кама артында беренче «Закамская засечная оборонительная линия» төзелә. Менә шушы чордан рәсми рәвештә төрле язмалар теркәлеп бара башлый.

Казан алынгач, азатлык өчен туктамый барган көрәшнең үзәге хәзерге Әлмәт һәм Лениногорск төбәкләрендә булуы — инде билгеле хәл. Сок һәм Кинель елгалары арасында да ул чорда бик катлаулы тормыш кайнаган. Бирегә чукындырудан качып килгән халык та, эзәрлекләнүче баш күтәрүчеләр дә, «бобыли» дип аталган буйдаклар да, 25-30 ел хезмәт иткән солдатлар да, җир ирege өмет итеп күчеп килгән крестьяннар да, хәтта күпсанлы баскынчы, качкын-каракляр да җитәрлек булганнар. Алар барысы да менә шушы бай табигатьле башкорт җирләренә килеп сыенганнар.

Монда төрле чорларда алардан казаклар да, хөкүмәт крестьяннары да ясаганнар. Башкорт җирләрен арендага алып җан асраучыларны «типтәрләр» дип тә йөрткәннәр.

Татар тарихын тирәнтен өйрәнгән Байтуган авылында яшәүче Әбүзәр абый Бәдретдинов биредәге башкорт биләмәләренә кергән җирләр «захолустье» булган дигән фикердә тора. Бу сүзләрдә дә, бәлки, дөреслек бардыр. Шушы җирләрдә төрле каты сугышлар булып узуы турында халык авыз иҗатында, таулар һәм башка җирләр атамасында күп серләр саклана. Әлбәттә, каты сугышлар булып торган җирләрдә утрак һәм тыныч тормышның булуы да шикле. Мәсәлән, бу тирәләрдә Батый хан гаскәрләре белән Болгар иле арасында каты сугыш булуы турында Татарстан тарихчылары яза. Тимур белән Тохтамыш арасындагы киң җәелгән сугыш та монда кагылган булса кирәк.

Кызганыч ки, татар тарихына кагылган бик күп чыганаклар вәхшиләрчә юк ителгән. Дөрес, бик тирәнгә кергән борынгы чыганакларның кайбер өлешләре сакланган. Тарихын барлаганда халык үз чыганакларына ныграк таянырга тиеш. Чит халык язмаларында улниләр генә язылмас. Кызганыч, әле Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән генә сакланып калган Болгар тарихы чыганакларына карата да һаман кырын караш яши. Менә алар:

1. Бахши Иманның «Җәгъфәр тарихы» (болгар елъязмалары җыентыгы);
2. Даиш Карачәй әл-Болгариның «Нариман тарихы»;
3. Кубан Бояның «Чулман толгау»ы;
4. Михаил Баштуның «Шан кызы дастаны»;
5. Васил Куш әл-Болгариның «Удивительные истории и повести - освежающие родники для идущих по Булгарскому пути» җыентыгы.

Бу хәзинәләрдә әле ачыкланмаган серләр тулып ята.

Менә безнең Камышлы төбәген алсак, андагы тарих серләре дә үзләрен ачыклауны күптән көтеп яталар. Камышлы авылында яшәгән Лотфулла Сафин авыл тарихы турында күп язмалар калдырган. Аларны Хуҗиәхмәт Санияхмәтов дәвам иткән.

Мондагы «Кылыч тау», «Тимер тырнак», «Туң каен» һәм «Зиратлы чогыл» тауларында төрле чордагы сугышларның эзләре калган. Элгәре аларда таш коймa белән тотылган каберлекләр булган. Шулай ук «Кустарлык артеле» каршындагы тауда да каберлекләр булган. Хәзер инде аларның эзләре дә калмаган. Ул урыннар сөрелгән яисә ташландык җиргә әверелгән.

«Минем әтием 1910 елда баз казыганда да кеше сөякләре килеп чыга. Анда гарәпчә язылган кабер ташы да була. Күршебез Гирфанов йортында да кабер булуы ачыклана. Болар киредән ябылып, билгеләнеп куела», - дип яза Лотфулла Сафин.

Монда, әлбәттә, тарихка карата битараф та, наданлык та, динсезлек сәясәте дә - барысының да чагылышы бар.

Менә шулай каберләр, каберлекләр эзсез югалган кебек, безнең тарихыбыз да югала бара. Әле якындагы еллардагы истәлекләр дә үз кыйммәтен югалтып, юкка чыга баралар. Бу - зур фаҗига. Болар - хәтер саегуының һәм күңел тарлыгының билгеләре.

***Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.***